ПРОЕКТ

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЮТАЗИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АБСАЛЯМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423957, Республика Татарстан,
Ютазинский район, с.Абсалямово,
ул. Молодежная д.2
т ел./факс: 4-26-79
E-mail: Absal.Utz@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
423957, Татарстан Республикасы,
Ютазы районы, Әбсәләм авылы,
Яшьләр урамы, 2
тел./факс:4-26-79
E-mail: Absal.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 3** **«29» январь 2026 ел**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсендә гражданнар җыенының 2025 елның 12 ноябрендәге 1 санлы карарын;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм авылында гражданнар җыенының 2025 елның 12 ноябрендәге 3 санлы карарын гамәлгә ашыру кысаларында,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru/ һәм "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы" челтәр басмасында Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru (2013 елның 17 декабрендәге Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын урнаштыру адресы буенча http://jutaza.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктлары территориясендә түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат

стендларында урнаштыру: Әбсәләм авылы, Яшьләр урамы, 2 йорт, Әбсәләм тимер юл разъезды поселогы, Тынычлык урамы, 3 йорт адреслары буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы: Г.В.Кубашева

Әбсәләм авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның “29” январь 2026
3 санлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 2026 елның 22 гыйнварыннан 2026 елның 28 мартына кадәр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге территориясендә 18 яшькә җиткән, гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә чагылдырылган мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ир белән хатын), Россия Армиясе сафларында ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 18 яшькә җиткән гражданнар (ата-аналар, ир белән хатын) тарафыннан срокта гамәлгә ашырыла.

3. Түбәндәге очракларда нигезле сәбәпләр булганда:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт тормау,

б) авыру,

гражданнарга түләүне гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерү юлы белән, шулай ук кул куеп тапшыру, я почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртү) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша акча күчерү юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын акча керү турындагы касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

8. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгән очракта, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Әбсәләм авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елның “29” январь
3 санлы карарына 2 нче кушымта

Әбсәләм авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ______________________________________________
Адресы: ___________________________________________________________
__________________________________________ нигезендә
___________________Сезгә ______________елның “___”____________кадәр
үзара салым түләү буенча узган җыен чараларын гамәлгә ашыру буенча түбәндәге реквизитлар буенча бер тапкыр түләнә торган сумма күчерергә кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО
Билгеләнгән түләү

Җитәкче _____________________________________________________
М.У. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Әбсәләм авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ _________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ______________________________________________
Адресы: ___________________________________________________________
«__» ________________ 20__ елны _________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Әбсәләм авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.